Фамилиягез ______________________________
Исемегез _________________________________
Әтиегезнең исеме________________________

Номерыгыз [        ]

# ТЫҢЛАП АҢЛАУ

Төп дәрәҗә: В2.

**30 минут**

## Биремнәр бланкы

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Биремнәр бланкының өске өлешенә фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исемен һәм номерыгызны языгыз. Шул ук мәгълүматларны 3 нче номерлы җаваплар бланкының өске өлешенә язып куегыз.
Сез җавап вариантларыгызны биремнәр бланкында да билгели аласыз. Биремнәрне эшләп бетергәч, җавапларыгызны махсус бланкка күчереп язарга онытмагыз. Инструктор биремнәрне эшләп бетерергә 10 минут кала сигнал бирәчәк.
Һәр бүлек башында эшне башкару өчен күрсәтмә һәм үрнәк бирелгән. Сез барлык биремнәрне үтәргә тиеш.
Биремнәрне эшләп бетергәч, биремнәр һәм җаваплар язылган бланкларны инструкторга бирегез.
Сорауларыгыз булса, Сез аларны хәзер бирә аласыз. Биремнәрне эшләгәндә, сораулар бирү һәм сөйләшү тыела.

## Тест турында кыскача мәгълүмат

Биремнәрне эшләү вакыты: 30 минут
Бүлекләр саны: 4
Биремнәр саны: 30
Баллар: һәр бирем 1 балл белән бәяләнә.
Гомуми баллар саны: 30

## ТЫҢЛАП АҢЛАУ

**1 нче бүлек**

**Сез сигез кыска монолог тыңларсыз. 1-8 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез. Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**0** **Сез бер әфәнденең сөйләмен ишетерсез. Аны бу спорт төренә кем дә булса өйрәткәнме?**

1) Ул мөстәкыйль рәвештә өйрәнгән.
2) Үзенең тренеры өйрәткән.
3) Башка ярышучылардан өйрәнгән.

| | |
|---|---|
| **0** | **1** |

**1** **Сез бер ирнең радиодан үз һөнәре турында сөйләгәнен ишетерсез. Ул ни өчен күптөрле һөнәри сыйфатларга ия булырга тиеш?**

1) Чөнки балалар күп кызыксыналар.
2) Чөнки аңа яңалыклар белән эш итәргә туры килә.
3) Чөнки ул бик намуслы кеше.

**2** **Сез вакытлы матбугат турында Айзиләнең чыгышын тыңларсыз. Ул нинди фикер әйтә?**

1) Вакытлы матбугат кызыклы булырга тиеш дип әйтә
2) Вакытлы матбугат хәзерге көнгә ярашлы булырга тиеш ди.
3) Вакытлы матбугат бай эчтәлекле булырга тиеш ди.

**3** **Сез бер бәйрәм турында мәгълүмат тыңларсыз. Ул ни өчен ай бәйрәме дип атала?**

1) Бәйрәмнең исеме дәүләт символлары белән бәйле.
2) Бәйрәмнең исеме төрле ел фасылларына бәйле.
3) Бәйрәмнең исеме күк җисеменең төрле торышына бәйле.

**4** **Сез бер ханымның уңышка ирешү серләре турындагы фикерен тыңларсыз. Аның танышы нәрсәгә өметләнгән?**

1) Ул аның булышуын теләгән.
2) Ул аның киңәш бирүен теләгән.
3) Ул аның уңышка ирешүен теләгән.

**5** **Сез сәламәтлек саклау министрының чыгышын тыңларсыз. Чыгышта кемнәр турында сүз бара?**

1) Мәктәптәге мөмкинлекләр турында.
2) Ярдәмгә мохтаҗ балалар турында.
3) Мәктәптәге шартлар турында.

**6** **Сез Ю.Гагарин турындагы истәлекне тыңларсыз. Аның дулкынланганын ничек аңлатырсыз?**

1) Галәмнән офыкны күргәнгә дулкынлана.
2) 108 минут буе галәмдә булганга дулкынлана.
3) Галәмгә беренче очыш җаваплы булганга дулкынлана.

**7** **Сез олимпия уеннарында катнашкан спортчы турында язма тыңларсыз. Ирекнең зур җиңүләре нәрсәгә бәйле?**

1) Җиңүләре ярышларда катнашуына бәйле.
2) Аның җыелма командада чыгыш ясавына бәйле.
3) Аның күп шөгыльләнүенә бәйле.

**8** **Сез төрле һөнәрләр турында мәгълүмат ишетерсез. Язмада нәрсә турында сөйләнелә?**

1) Төрле һөнәрчеләрнең бер-берсенә охшавы яки аерылып торуы турында
2) Төрле хезмәтләрнең бер-берсенә охшавы яки аерылып торуы турында.
3) Төрле хезмәткәрләрнең бер-берсенә охшавы яки аерылып торуы турында.

**2 нче бүлек**

**Спорт министры урынбасары белән интервьюны тыңлагыз. 9-18 нче биремнәргә туры килгән җавапны сайлагыз. Сез интервьюны ике тапкыр тыңларсыз.**

Казанга килүче туристлар саны спорт (9) _______________ белән бәйле арта бара.

Ярышлар арасында (10) __________________ ату, трамплиннан (11)_________________, академик (12) _______________ кебек спорт төрләренең булуы да куанычлы.

Шәйхетдинов үзенең чыгышында киләчәктә төзеләчәк яңа спорт (13) _______________ турында сөйли.

Балалар белән эшли торган (14) _______________________ төрле урыннардан чакырылуы да билгеле булды.

Төрле ярышларны оештыруда ярдәм итүчеләр, ягъни (15) _______________ күп булуы спорт министры урынбасарын шатландыра.

Шәйхетдиновның хәбәр итүенчә, алдагы елда уздырылачак ярышлар арасында җиңел атлетика буенча дөнья (16) _____________ дә бар.

Хәлил әфәнде балаларын кечкенәдән (17) _________________ өйрәтүе белән горурлана.

Хәлим әфәнде фикеренчә, спорт белән (18) _______________ сәламәтлекне ныгыта.

**3 нче бүлек**

**Сез биш кыска монолог тыңларсыз. 19-23 нче сорауларга туры килгән А-Д җавапларын сайлагыз. Һәр сорауга бер генә хәреф туры килә. Бер җавап артык.**

| | |
|---|---|
| А Мин рәхәтләнеп тәмле ризыклар ашап карадым. | I сөйләүче___________________ (19) |
| Ә Мин кып-кызыл диңгез эчендә калдым. | II сөйләүче____________________ (20) |
| Б Төрле төскә кереп беткәнемне сизми дә калдым. | III сөйләүче__________________ (21) |
| В Бәйрәм киемнәре миңа бик ошады. | IV сөйләүче__________________ (22) |
| Г Ел башы бәйрәменең хуҗасын кайдан эзләргә дә белмим. | V сөйләүче___________________ (23) |
| Д Иң кадерле кешемне котлаячакмын. | |

**4 нче бүлек**

**Сез Марлиз ханым белән сөйләшүне тыңларсыз. 24-30 нчы биремнәрдәге сорауларга А, Ә һәм Б җавапларының дөресен билгеләгез. Сез сөйләшүне ике тапкыр тыңларсыз.**

**24** Марлиз ханым Татарстанга ни өчен килгән булган?

А) Ул үзгәртеп кору турында фәнни хезмәт язарга теле.

Ә) Ул җирле халык турында күбрәк белергә теле.

Б) Ул фәнни җитәкчесе белән очрашырга теле.

**25** Марлиз ханым татар мәдәнияте турында каян белгән?

А) Ул турыда аңа җитәкчесе сөйләгән.

Ә) Яңа проектта эшләгәндә белеп калган.

Б) Яңа фәнни хезмәте аша белгән.

**26** Марлиз ханымга Казандагы корылмаларның берсе ни өчен ошый?

А) Чөнки ул корылманың төзелеп ятуын күзәтеп торган була.

Ә) Чөнки ул корылма бизәлеше белән җәлеп итеп тора.

Б) Чөнки ул корылма уңышлы гына эшләп килә.

**27** Марлиз ханым киләчәккә хыяллары турында нәрсәләр сөйли?

А) Аның киләчәктә русча язылган текстлар белән эшлисе килә.

Ә) Аның киләчәктә журналист булып эшләп карыйсы килә.

Б) Аның киләчәген фәнни юнәлеш белән бәйләп карыйсы килә.

**28** Марлиз ханым алман галиме турында ишетмәвен ничек аңлата?

А) Галим турындагы мәгълүматларны белмәгән.

Ә) Галим турындагы мәгълүматлар аның өчен кызык булмаган.

Б) Галим турындагы мәгълүматлар аның максатына ярашлы булмаган.

**29** Марлиз ханым татар язучысының бер әсәрен ни өчен сайламаган әле?

А) Чөнки аның үзе белән бәйләнешкә кереп сөйләшәсе бар.

Ә) Чөнки ул язучының барлык әсәрләрен дә укып чыкмаган әле.

Б) Чөнки аны кызыксындырган әсәрне сайлап алу мөмкин түгел.

**30** Марлиз ханым ни өчен татар язучысының әсәрләрен алман теленә күчерә алуына ышана?

А) Чөнки ул татарларның тормыш-көнкүреше, мәдәни үзенчәлекләре турында күп белә.

Ә) Чөнки ул татарларның тормыш-көнкүреше, мәдәни үзенчәлекләре турында өйрәнергә тели.

Б) Чөнки татарларның тормыш-көнкүреше, мәдәни үзенчәлекләре алманнар өчен кызык.

**Җавапларны  махсус бланкка  күчерү өчен,  6 минут вакытыгыз бар.**

Фамилиягез ______________________
Исемегез ________________________
Әтиегезнең исеме__________________

Номерыгыз

**УКУ**

**Дәрәҗә: B2**

**1 сәгать 15 минут**

**Биремнәр бланкы**

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Биремнәр бланкының өске өлешенә фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исемен һәм номерыгызны языгыз. Шул ук мәгълүматларны җаваплар бланкының өске өлешенә язып куегыз.
Сез җавап вариантларыгызны биремнәр бланкында да билгели аласыз. Биремнәрне эшләп бетергәч, җавапларыгызны җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз. Инструктор биремнәрне эшләп бетерергә 10 минут кала сигнал бирәчәк.
Һәр бүлек башында эшне башкару өчен күрсәтмә һәм үрнәк бирелгән. Сез барлык биремнәрне үтәргә тиеш.
Биремнәрне эшләп бетергәч, биремнәр һәм җаваплар язылган бланкларны инструкторга бирегез.
Сорауларыгыз булса, Сез аларны хәзер бирә аласыз. Биремнәрне эшләгәндә, сораулар бирү һәм сөйләшү тыела.

## Тест турында кыскача мәгълүмат

Биремнәрне эшләү вакыты: 1 сәгать 15 минут
Бүлекләр саны: 7
Биремнәр саны: 52
Баллар: 1-24 һәм 43-52 нче биремнәрдә дөрес җавап - 1 балл, 25-30 нчы биремнәрдә – максимум 2 балл һәм 31-42 нче биремнәрдә 2 балл белән бәяләнә.
Гомуми баллар саны: 70

# УКУ

**1 нче бүлек**

**Текстны укыгыз һәм 1-8 нче биремнәрдәге туры килгән сүзне үрнәктәгечә билгеләгез.**

**ҮРНӘК:**

**0** А) өйрәнү Ә) өйрәтү Б) аралашу В) шөгыльләнү

| | |
|---|---|
| 0 | А |

## Нәсел шәҗәрәсе

Нәсел тарихлары белән кызыксыну күп халыкларга мәгълүм. Татар халкының да үзенчәлекле гаилә традициясе бар. Ул – нәсел шәҗәрәсен (0) _________ һәм белү. Шәҗәрә (1) ________ халык ата-бабаларыбызның тарихын, яшәү рәвешен, нәселне дәвам итүен белгән. Шәҗәрәне өйрәнү мәсьәләләре Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Ибраһимов хезмәтләрендә дә тикшерелә.

Ата-бабаларның нәсел (2)___________ белү һәм саклау – аларга хөрмәт ул. Һәркемнең гаиләсендә (3) _______________ итеп куярлык традицияләр, нәселдән-нәселгә күчә барган гадәтләр, шатлыклы вакыйгалар бар. Гаилә (4) ____________ кадерләп саклау, үз нәселеңнең абруе турында кайгырту да мөһим. Нәсел чылбырында үзенең булуын тою кешедә нәселе белән горурлану тойгысы тәрбияли. Шуңа күрә нәсел шәҗәрәсен өйрәнү һәм терки бару (5) ___________________.

Нәселеңне белү – ул туганнар белән аралашу, аларның хәлен белеп тору дигән сүз. Хәзерге вакытта гаиләң белән (6)____________ да сирәк бер күренеш була бара. Бу хәл буыннар арасындагы мөнәсәбәтләрнең суынуына китерә, гаилә традицияләренең (7) _____________ көчүен тоткарлый. Шуңа күрә иң мөһиме: һәр әби-бабай һәм ата-ана үз баласына нәсел шәҗәрәсендәге бабаларның тормышы, эш-гамәлләре турында сөйләп, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләргә, гадәт-йолаларны балаларга (8) ______________ тиеш.

**1** А) аркылы Ә) турында Б) өчен В) булып

**2** А) торышын Ә) тарихын Б) күренешен В) гадәтен

**3** А) хөрмәт Ә) хәл Б) гамәл В) үрнәк

**4** А) хәлен Ә) мәсьәләләрен Б) истәлекләрен В) көндәлекләрен

| 5 | А) әһәмиятле | Ә) тиеш | Б) мәгълүм | В) шатлыклы |
|---|---|---|---|---|

| 6 | А) аралашу | Ә) саклау | Б) кайгырту | В) күчү |
|---|---|---|---|---|

| 7 | А) бер-бер артлы | Ә) буйдан-буйга | Б) буыннан-буынга | В) елдан-ел |
|---|---|---|---|---|

| 8 | А) сакларга | Ә) тапшырырга | Б) дәвам итәргә | В) кайгыртырга |
|---|---|---|---|---|

**2 нче бүлек**

**Текстны укыгыз һәм 9-16 нчы биремнәрдәге текстның эчтәлегенә лексик һәм грамматик яктан туры килгән БЕР сүзне табыгыз. Җаваплар бланкында сүзне БАШ ХӘРЕФЛӘР белән языгыз.**

**ҮРНӘК:**

| 0 | Д | И | П |
|---|---|---|---|

**Жокей**

Миңа әтием Фокус исемле, Mini Horse токымлы ат бүләк иткән иде. Аны күрергә (0)__________, көн саен ипподромга йөри башладым. Шунда булачак тренерым (9) ___________ таныштым. Ун яшемдә беренче тапкыр атта чаптым. Ундүрт яшьтән бирле ат чабышларында катнашып киләм.

Ат – иң акыллы хайван, ул барысын (10) ___________ аңлый, ә аның уртак тел таба белү – жокей эше.

Бервакыт, үземне сынап карар өчен, көне (11) ___________ атта чаптым. Икенче көнне атны тыныч кына йөртергә кирәк иде. Бер чабарга өйрәнгән атны тиз (12) ___________ тынычландырып кара син! Менеп утыруга, алга чапты. Каршыда сигез метрлы чокыр. Атым тагын ике метрдан борылмаса, сикерәм (13) ___________ хәл иттем. Ничек кенә булса да, бу чокырны әйләнеп уздык. Хәзер аңлыйм: бу хәлгә минем тәҗрибәсезлегем сәбәпче булган.

Барлыгы сигез ат чабышында катнаштым, алтысында җиңү яуладым. Атны дөрес позициягә бастырып бару (14) ___________, бик күп көч кирәк. Тренировкадан (15) __________ егерме минут бармакларымны турайта алмаган чаклар да була.

Һәр атның үз характеры бар. Нинди генә әйбәт жокей булуга (16)_____________, ат характерын тулысынча ачып бетерә алмыйсың. Шәхси тәҗрибәмнән бер нәтиҗәгә килдем: атларга көчле икәнлегеңне күрсәткәндә генә, алар сине тыңлый башлый.

**3 нче бүлек**

**Текстны укыгыз. Уң якта баш хәрефләр белән бирелгән сүзләрне 17-24 нче биремнәргә лексик һәм грамматик яктан туры килерлек итеп үзгәртеп языгыз.**

**ҮРНӘК**

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **0** | **С** | **У** | **Ы** | **К** | **Н** | **Ы** |

| | |
|---|---|
| Кар – җирнең туны сыман. Ул җирне каплап ала да андагы җылыны тышка чыгармый, ә (0) **__________** үткәрми. | СУЫК |
| Карның әлеге сыйфаты (17) ________ һәм хайваннар өчен файдалы. (18) _______ кар көз ахырында ява һәм дөньяга кыш җитүе хакында хәбәр итә. Кар шәһәр | ҮСӘРГӘ<br>БЕР |
| һавасын да чистарта. Кышын (19)____________ һава суларга, чана-чаңгы шуарга да була. | РӘХӘТ |
| Яуган вакытта ул һаваны сафландыра, тузанны үзенә сеңдерә. (20) ______ кар ничаклы күбрәк җыелса, җирнең дымы шулчаклы булачак. Яз көне кар эри | КЫШ |
| һәм ташу яки (21) ____________ булып ага, урманнарны,басуларны, бакчаларны дым белән сугара. Ә бу,үз чиратында, үсемлекләр, агачлар өчен | ГӨРЛӘРГӘ |
| (22) **__________**. | ФАЙДА |
| Җир шарында иң күп кар яву күренеше 1971 нче елда АКШта Раньер тавында күзәтелә. Бу вакытта тау итәкләренә 30 метрдан артык кар ява. | |
| Кар күп яву зыян да китерергә мөмкин. Өстәвенә, җил чыгып,буран да котыра башласа, (23) **_________** оча алмый, поездлар кузгалмый, автомобиль юллары ябыла. | ОЧАРГА |
| Юлларга салган карны (24) __________ күп вакыт кирәк. | ЧИСТА |

**4 нче бүлек**

**25-30 нчы биремнәрдә, беренче җөмләнең эчтәлегенә туры китереп һәм БАШ ХӘРЕФЛӘР белән бирелгән сүзне кулланып, икенче җөмләне үзгәртмичә тулыландырыгыз. Һәр җөмләдә икедән ким, биштән артык сүз кулланырга ярамый. Җаваплар бланкына бары тик шул сүзләрне генә языгыз.**

**ҮРНӘК**

**0** Билетлар сатып алгач, без шатлана-шатлана сәяхәткә кузгалдык.

**ШУННАН СОҢ**

Без билетлар _______________,___________шатлана-шатлана сәяхәткә кузгалдык.

**САТЫП АЛДЫК ШУННАН СОҢ**

**25** Кайберәүләр табигатьтә актив ял итәләр, шуның өчен диңгез буен яки тауларны сайлыйлар.

**МАКСАТЫННАН**

Кайберәүләр табигатьтә актив __________________, диңгез буен яки тауларны сайлыйлар.

**26** Күптән чит илдә булганым юк, шуңа күрә мин үземнең ял вакытымны сәяхәттә уздырырга телим.

**КҮРӘ**

Күптән чит илдә _________________, мин үземнең ял вакытымны сәяхәттә уздырырга телим.

**27** Кунакханәләрдә яшәү өчен бәяләр артса да, чит ил туристларына Россиягә килү отышлы булачак.

**ШУҢА КАРАМАСТАН**

Кунакханәләрдә яшәү өчен бәяләр _______________, _______________чит ил туристларына Россиягә килү отышлы булачак.

**28** Экскурсиягә кайчан һәм нинди транспорт белән барып булуын ачыклагыз.

**ШУНЫ**

Сез ______________________: экскурсиягә кайчан һәм нинди транспорт белән барып була.

**29** Тиздән самолетка утырту башланасын хәбәр иттеләр.

**ДИП**

Тиздән самолетка утырту ____________________хәбәр иттеләр.

**30** Мин дусларымнан “Ничек ял иттегез?” дип сорадым.

**ТУРЫНДА**

Мин дусларымнан ничек ________________________ сорадым.

**5 нче бүлек**

**Романнан алынган өзекне укыгыз. 31-36 нчы биремнәрдәге сорауларга туры килгән җавапны билгеләгез.**

Һиндстанның бөек мөмкинлекләр иле икәнлеген мин Бомбей урамнарында йөргәндә аңладым. Бу илдә күргәннәрне гади генә аңлатып булмый. Монда агачларның очлары болытларга тиеп тора. Шәһәр урамнарында үскән агачларның тамырлары һавада асылынып тора. Нигә алар җирдә түгел? Җир артык юеш булгангамы? Һиндстан искә төшкән чакта, күз алдыма шул гигант тамырлар килеп баса... Нәрсә очравын, кемгә юлыгуыңны алдан белмичә, ят калада адашып йөрүдән дә мавыктыргыч нәрсә бармы икән бу дөньяда? Байлар яши торган урамга килеп чыккач, мин туктап, бераз аптырап тордым. Киң матур урам, аның йортлары, бакчалары, анда үскән чәчәкләр, Урта диңгезнең зәңгәр ярлары буендагы виллалар, Лос-Анджелес миллионерлары яши торган йортлар шундагы бакчаларда үскән чәчәкләргә охшаган...

Һиндстан исемә төшкәндә, Бомбей урамында басып торган гигант фил күз алдыма килеп баса. Филнең алгы аягын чылбыр белән җиргә каккан баганага бәйләгәннәр. Мескен фил яныннан узучыларга тез чүгә дә, хобытын сузып, акча сорый. Үтеп баручылар аңа вак акча ташлыйлар. Фил, акчаны җирдән алып, хуҗасына тапшыра. Бәхетсез фил аңлыймы икән мескенлекнең ни икәнен? Фил – көчле хайван, ләкин ни сәбәпледер, кешеләр алдында ул баш ия. Адәм баласының боерыгы кешеләрне генә түгел, башка җан ияләрен дә буйсындыра ала, хәтта филне, агулы еланны да.

Күргәннәрне тәртипкә салырга көч җитми. Әнә каршымда елан биетүче карт басып тора. Искиткеч ябык. Аяк-куллары шундый нечкә. Чал төшкән куе бөдрә чәч. Битләрен тирән җыерчык баскан. Елан биетүче аякларын бөкләп, җиргә утырган да флейта уйный. Озын салмак көй безнең әбиләрнең җырларын хәтерләтә. Күзлекле елан – кеше өчен иң куркыныч агулы җан иясе. Елан көне буе кешегә тамаша күрсәтеп йөреп арыган. Флейта тавышы еланны куа. Музыканың көченә исем китә. Адәм баласын гына түгел, җәнлекләрне, ул хәтта агулы еланны да үзенә буйсындыра ала икән ул. Елан, теләр-теләмәс кенә, башын күтәрә башлады. Баш өскә, югарыга күтәрелә, гәүдә турая, үсә бара. Бервакыт күзлекле елан туп-туры булып сузылды, койрыгына басты. Флейтаның салмак көе, кыска ритмнарга бүленеп, бию көенә әйләнде. Көй хәзер ашыктыра иде. Елан хәрәкәткә килде, гәүдәсен дулкынландырып селкетә, бии иде ул. Чүлдә күрсәм, мин бу еланнан куркыр идем. Чакса,

һичшиксез, үтерәчәк, чөнки агулы елан. Ә хәзер нигәдер кызганыч күренде ул миңа.

Бу илдә бер нәрсәнең дә чиге-чамасы юк. Хәтта табигать тә монда башка кануннар буенча эшли. Әле яңа гына аяз, кояшлы иде. Минут эчендә күкне тоташ болыт каплап алды. Әйтерсең шушы болытлар өстеннән мул сулы елгалар ага иде – шарлавык булып, күктән яңгыр коя башлады. Әнә тәгәрмәч астыннан су чәчрәтеп, урам уртасыннан рикша йөгерә. Сатучылар кибет витриналары өстенә чатырларын ачып җибәрделәр. Ярлы халык башына газета бөркәнде, хәерчеләр ышыграк җиргә шуышып утырды. Әйтерсең бу яңгырны аллаһы тәгалә, гомерләрен урам ташында уздыручы кешеләрнең догаларын кабул итеп, аларны эсселектән саклар өчен җибәрде. Һәр очраган кешенең йөзендә канәгать елмаю балкый иде.

Һиндстанда ел фасыллары да бөтенләй башкача. Монда яз – җәйгә, җәй – көзгә, көз кышка алышынмый. Елның дүрт фасылына күнеккән кешегә Һиндстандагы үзгәрешләр шактый сәер тоела. Һиндстанда ел бары тик өч фасылдан тора: җәйге муссон алып килгән юеш эсселек чоры, кышкы муссон китергән кышкы җиләслек чоры, һәм муссон алышынган чактагы кайнар эсселек. Әгәр мондагы эсселекнең бер өлешен тундрага җибәреп, аның туңлыгын эретсәң һәм Котыптагы салкынлыкның бер өлешен мондагы эсселеккә алыштырсаң! Ләкин табигатьне көчләп буйсындыра башласалар, ул үлә, юкка чыга. Котыптагы салкынлык белән тропик эсселекне бергә кушып ясаган уртача температура минем туган авылым Исергәптә. Андагы һаваның яшәү өчен иң кулай икәнен Котыпка яки тропикка эләккәч кенә аңлыйсың.

Нинди хикмәтле ил бу Һиндстан! Бу илдә яшәү фәлсәфәгә бәйле. Аларның диннәре, көнкүрешләре, эшләре, теләкләре – барысы да фәлсәфәгә төрелгән. Көтә, өмет итә белү – аларның каннарында, сулыш алуларында. Нәрсәдәндер юаныч таба белә бу кешеләр. Яшәү өчен кирәкле бер нәрсәләре дә юк мескеннәрнең, ә күз карашларында – өмет, йөзләрендә, хәрәкәтләрендә – тынычлык. Бәхетле булу өчен, күпкә омтылмаска, күпне теләмәскә кирәк. Аларның яшәү фәлсәфәсе шушы кагыйдәгә сыеп бетә диярлек... Бомбейдан төньякка, Калькутта портына барабыз. Караңгы төшеп килә. Һималай таулары, чүлләр, елгалар артта калды...

(М. Юныстан)

**Автор Һиндстанның нинди ил булуын тасвирлый?**

**31** А) мавыктыргыч ил булуын

Ә) кунакчыл ил булуын
Б) могҗизалы ил булуын
В) танылган ил булуын

**32** **Автор, фил турында сөйләгәндә, нәрсәгә игътибар итә?**
А) фил хуҗасына хезмәт итә
Ә) фил сәяхәтчеләрне куркыта
Б) фил халыкка тамаша күрсәтә
В) фил кешеләргә хыянәт итә

**33** **Автор күзлекле еланны ни өчен кызгана?**
А) агулы җан иясе булганга
Ә) халык алдында чыгыш ясаганга
Б) эссе чүлдә интегеп яшәгәнгә
В) адәм баласына буйсынганга

**34** **Автор Һиндстанның табигатен ничек сурәтли?**
А) Һава торышы тотрыклы.
Ә) Алмашынучан болытлы һава.
Б) Һава торышы еш үзгәрүчән.
В) Ел әйләнәсе кояш балкый.

**35** **Автор Һиндстандагы ел фасыллары турында нинди фикердә?**
А) Ел фасыллары гадәттәгечә алмашына.
Ә) Ел фасыллары гадәттәгедән аерыла.
Б) Ел фасыллары туган як табигатенә охшый.
В) Елның дүрт фасылы да ямьле.

**36** **Автор фикеренчә, яшәү фәлсәфәсе нәрсәдән гыйбарәт?**
А) Кеше тыныч күңел белән яшәргә тиеш.
Ә) Кеше бәхетле тормышка омтылырга тиеш.
Б) Кеше азга канәгать булырга тиеш.
В) Кеше теләк, хыяллар белән яшәргә тиеш.

**6 нчы бүлек**

**Курчак театрында эшләүче өлкән артистның үз һөнәре турында сөйләгән газета мәкаләсен укыгыз. Мәкаләдән алты җөмлә кисеп алынган. 37-42 нче биремнәрдә тәкъдим ителгән А-Е җөмләләрен тексттагы төшеп калган урыннарга туры килерлек итеп сайлагыз. Биремдә бер җөмлә артык.**

## Тормыш әкияттән башлана

Әдәбиятка, курчакларга мәхәббәт, әлбәттә, эти-әниемнән килә. Безнең гаилә актерлар гаиләсе белән якыннан аралаша иде. Минем алты яшьләрдә клоун тотып төшкән фотом бар. Бала чагымда уенчыкларым, курчакларым бик күп булды, дияргә мөмкин. **[37]** Шуңа күрә дә курчак театры артисты һөнәрен сайлау очраклы булмады.

Санкт-Петербургта белем алганнан соң, мин Казанда “Әкият” курчак театрында эшли башладым. Төрле кызыклы рольләрдә уйнарга туры килде. А.Гайдарның режиссер Игорь Москалев куйган “Смелая сказка” әсәрендәге Мальчиш-Кибальчиш, А.Экзюпериның “Маленький принц”ында Малай һәм башка рольләрне уңышлы башкардым. “Кәрлә – мәктәп баласы”, “Авыл эте Акбай” һәм башка әсәрләрендә уйнадым. Шулай итеп, курчаклар дөньясы мине тулысы белән бөтереп алды. **[38]** Әйтик, курчак театры артисты өчен юмор остасы булу, балалар күңелен аңлау сорала. Шуңа күрә безнең эштә психолог та булырга кирәк.

Безгә төрле курчаклар белән уйнарга туры килде. Иң җиңеле – курчакның бармакларга киеп уйный торганы. Авыры – чыбык-җепләр белән тартып уйнау. Рәссам, аларны ясаганда, артисттан сорап тормый, ул режиссер белән киңәшә. Башка артистлардан аермалы буларак, без нәни тамашачы белән аралашып уйныйбыз. Мин сәхнә алдында уйнаганда, залдан берәр ягымлы күз эзлим. Ул миңа көч бирә. Ширма артында уйнаганда да, аларның ничек кабул итүләрен тоеп була. Артистның уйнавы балалар кәефеннән дә тора. Алар спектакльдән соң уйланырга тиеш. **[39]** Бервакыт уйнаган чакта минем курчагым сәхнә алдына төшеп китте.Шунда бер бала урыныннан сикереп торды да: «Менә Сезнең курчагыгыз егылып төште!» – дип, аны миңа китереп тоттырды.

Курчак театрындагы спектакльләрнең балаларны тәрбияләүдә роле бик зур. Әкиятләр аша балаларны акны карадан, яхшыны яманнан аерырга өйрәтәбез. Кечкенәләр өчен хәерле иртә дияргә, теш чистартырга, физзарядка ясарга өйрәткән спектакльләребез бар. Могҗизалы һәм әкияти тамашалар йортында балалар яраткан әкият геройлары белән очрашып, театр сәнгате белән танышып кына калмыйлар, тәртипкә дә өйрәнәләр. **[40]** Персонажлар аркылы алар үзләренә кирәкле беренчел дәресләрне алалар.

Минем тормышым – театр, ул минем яшәү рәвешем. Минем репертуарым бай: аларда халык әкиятләре, тарихи һәм заман тематикасына караган спектакльләр тәкъдим ителә. Тамашаларда классик системалардан модерн стилендәгеләргә кадәр төрле курчаклар

кулланыла. Минем өчен иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе – бала, театрга килгәч, театр сәнгатенә гашыйк булып кайтып китәргә тиеш. Аның бинасы ук баланы театр сәнгатенә җәлеп итәргә тиеш. Бала күңеле ак кәгазь кебек, без анда нәрсә язабыз – бик күп нәрсә курчак театры артистыннан тора. Мин һаман эзләнәм, чит илләргә йөрим, чагыштырам. Үзгәртәсе, өйрәнәсе нәрсәләр шактый дип уйлыйм. Мәсәлән, заман балаларына заманча курчаклар кирәк. Элеккеге репертуардагы пьесаларның курчаклары хәзерге зур сәхнәгә ярамый, ә репертуарны тиз генә тулысынча яңартып бетереп булмый. **[41]**

Курчак театры – чын мәгънәсендә могҗизалар иле ул. Курчак театры артистлары, беренчедән, балаларга шатлык өләшсә, икенчедән, алар башка театрлар өчен тамашачы да әзерли. Минемчә, бу театрда бары тик балаларны яраткан артист кына эшли ала. Алар үзләренең самими булулары белән һәрвакыт балачак илендә калалар сыман тоела. Танылган бер театр белгече шулай дигән: «Балалар театрының максаты – күңел ачу аша тәрбия бирү”. **[42]** Кайсы гына әти-әнинең үз баласын тәүфыйклы, итагатьле, кече җанлы итеп үстерәсе килмәсен! Ә болар барысы да курчак театрында бит инде... Әкият дөньясында болар!

(*Вакытлы матбугаттан*)

**А.** Кыскасы, эшлисе эшләр, максатлар әле бихисап.
**Ә.** “Бер спектакль карау алтмыш дәрескә тора” дигән гыйбарә бар.
**Б.** Бу уңышым киләчәктә һөнәри үсешемә юл ачты.
**В.** Мин бу сүзләрне һәрвакыт истә тотарга тырышам.
**Г.** Балалар белән төрле кызык хәлләр дә була**.**
**Д.** Кечкенәдән серле сәхнә һәм сәхнә арты тормышы мине үзенә тартты.
**Е.** Аның үзенчәлекләре, курчаклар белән уйнау серләре әсир итте.

**7 нче бүлек.**
**Танылган теннисчы турында газета мәкаләсен укыгыз. 43-52 нче биремнәргә туры килгән өлешләрнең (А-В) берсен билгеләгез. Абзацлар бер тапкырдан күбрәк кулланылырга мөмкин.**

**Марат Сафин - танылган теннисчы**

**А.** Спорт зур уңышларга, көтелмәгән борылышларга бай: бер көн эчендә бөтен дөньяга танылып була. Марат Сафинга танылу егерме яшендә килә. 2000 нче елда АКШның ачык чемпионатында җиңү яулавы белән Марат

**Б.** Күп кенә яшьтәшләреннән аермалы буларак, аның байлыкка, яхшы киемнәргә, машиналарга исе китми. АКШтагы сенсацион җиңүдән соң, 800 мең долларлык чекка ия булган Мараттан журналистлар: “Бу акчаңны

тамашачыларны гына түгел, күп кенә теннис белгечләрен дә таң калдыра. Кичә генә миллионлаган теннис сөючеләрнең кумиры булган Пит Сампрас (АКШ), финалда Маратка җиңелгәннән соң, көндәшен “XXI гасыр уенчысы” дип атый. Атаклы теннисчыларның тагын берсе – Джон Макинрой исә: “Бу әле уңышның башы гына,” – дип өсти.

Маратның исә ул чакта җиңү шатлыгын озаклап бәйрәм итәргә вакыты да булмый. Ул Нью-Йорктан туп-туры Ташкентка – Үзбәкстан Президенты кубогына үткәрелгән турнирга оча. Анда барлык көндәшләрен җиңеп, ял итеп тә тормыйча, Ислам Кәримов җибәргән самолетта Сиднейдагы Олимпия уеннарына китә. Тик беренче әйләнештә үк француз Фабрис Санторога оттыра.

Марат уң кулы белән дә, сулы белән дә көчле итеп суга ала. Иң мөһиме: бер генә йолдыз белән дә уйнаудан курыкмый.

**Ә.** Күпләрдә “Кем соң ул Марат Сафин, кайсы яктан, шулай оста уйнарга кемнән өйрәнгән?” кебек сораулар туарга мөмкин.

Марат – Мәскәү егете. Әнисе Роза Исланова – теннис буенча күп тапкыр СССР чемпионы. Әтисе Мөбин Сафин – теннис клубы директоры. Марат кортка тәүге тапкыр биш айлык вакытында “аяк баса”. Калдырыр кешеләре булмагач, әнисе аны үзе белән нәрсәгә тотасың? Машина аласыңмы?” – дип сорыйлар. Теннисчы исә бер дә исе китмичә: “Нәрсәгә миңа машина?!” – дип җавап бирә.

Марат Сафин – гадел кеше. Мәсәлән, төп көндәшләренең берсе Бразилия теннисчысы Густаво Куэртен белән уйнаганда, хөкемдар “сызыктан кырыйга төште” дип, бразилияленең бер тубын санамый. Шунда Марат, хөкемдар янына килеп: “Тупны санагыз, бу очракта Куэртен хаклы,” – ди.

Спортчы тормышы җиңүләрдән генә тормый. Маратның да көндәшләре бар. Шуларның берсе – Фабрис Санторо. Теннисчылар арасында үткән җиде очрашуның бишесендә Санторо җиңү яулый. Оттырган вакытларда Маратның, кызып китеп, ракеткасын да сындыруы, тамашачыларга ыргытуы һәм шуның өчен шактый гына суммада штрафлар түләве дә билгеле.

**В.** 2000-2005 нче елларда Марат теннисчылар арасында иң күп акча эшләүче булып танылa. Мәсәлән, 2002 нче елда дүрт зур турнирда җиңүе аңа 2 миллион доллардан артык акча китерә.

Спорт дөньясы уңышлардан гына түгел, авырлыклардан да тора. Элегрәк байлар, корольләр, патшалар гына уйный ала торган теннис кебек спорт төрендә дә балкып янучылар янында

күнегүләргә алып килә. Тәпи басып йөри башлагач, ул әнисе группасында шөгыльләнүче балалар янында йөри. Ара-тирә кулына ракетка да алгалый. Тик аңа ракетканы ничек тотарга, теннис тубына ничек сугарга кирәклеген аңлатып торасы булмый. Малай барысын читтән күзәтеп, үзләштереп бетергән була инде.

Улына үз белемен, осталыгын биреп бетергәч, әнисе 14 яшьлек малайны Испаниягә җибәрә. Ул 15 елдан артык Малага шәһәрендә яши. Испан һәм инглиз телләрен өйрәнә һәм Валенсиянең Танчо Альверина Теннис академиясен тәмамлый.

сүнүчеләр бар. Бүген син – кумир, иртәгә дәрәҗәле урыныңны башкалар алырга мөмкин.

Иң мөһиме: зур җиңүләр яулаган спортчылар спорт тарихында да, җанатарлар күңелендә дә мәңгегә кала. Милләттәшебез Марат Сафин да – шундый дәрәҗәле уенчыларның берсе. Ул Бөтендөнья теннис ассоциациясе квартал саен диярлек төзи торган рейтингта унике атна буенча беренче урынны ала. “Зур шлем” ярышларына керүче төп дүрт турнирның икесендә җиңә һәм, ниһаять, дөньяның иң көчле командасы гына яулый ала торган Дэвис кубогына да ия була.

**Кайсы абзацта:**

| | | |
|---|---|---|
| Теннисчының көндәшләренә карата төрле алымнар куллана алуы искәртелә? | **43** | |
| Спортчыларга уңышның җиңел бирелмәве ассызыклана? | **44** | |
| Теннисчының зиннәтле тормышка кызыкмавына мисал китерелә? | **45** | |
| Марат Сафинның, күп тапкырлар җиңү яулап, спорт тарихында тирән эз калдыруы әйтелә? | **46** | |
| Маратның киләчәктә өметле спортчы булу мөмкинлеге искәртелә? | **47** | |
| Спортчының чит илдә белем алуы әйтелә? | **48** | |
| Теннисчының принципиаль һәм шул ук вакытта кызу канлы кеше булуы күрсәтелә? | **49** | |
| Маратның спорт дөньясына бик иртә килүе әйтелә? | **50** | |
| Марат Сафинның җиңелгән очраклары да шактый булуы искәртелә? | **51** | |
| Теннисчының әнисеннән беренче дәресләрне алуы турында искә төшерелә? | **52** | |

Фамилиягез ________________________
Исемегез __________________________
Әтиегезнең исеме__________________
Номерыгыз [ ]

## ЯЗУ

**Дәрәҗә: В2**

**1 сәгать 20 минут**

### Биремнәр бланкы

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәр бланкының өске өлешенә фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исемен һәм номерыгызны языгыз. Шул ук мәгълүматларны җаваплар бланкының өске өлешенә язып куегыз.

Биремнәрне башкарыр алдыннан күрсәтмәне игътибар белән укыгыз.

Сезгә 1 нче һәм 2 нче бүлектәге сорауларга җавап язарга кирәк була.

Һәр бүлек башында эшне башкару өчен күрсәтмә һәм үрнәк бирелгән.

Сез барлык биремнәрне үтәргә тиеш. Сез биремнәрне җаваплар бланкында башкара аласыз. КАЛӘМ белән аңлаешлы итеп язу сорала, ихтыяҗ туганда, төзәтмәләр кертү рөхсәт ителә.

Биремнәрне башкаруга 1 сәгать 20 минут вакыт бирелә. Сез күрсәтелгән вакытка эшләрегезне тәмамларга тиеш.

Биремнәрне эшләп бетергәч, җавапларыгызны җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз.

Биремнәр һәм җаваплар язылган бланкларны инструкторга бирегез.

Һәр сорауга җавап бер төрле баллар белән бәяләнә.

**Тест турында кыскача мәгълүмат**

Биремнәрне эшләү вакыты: 1 сәгать 20 минут

Бүлекләр саны: 2

Биремнәр саны: 2

Баллар: 1 нче бирем – 14 балл белән, 2 нче бирем 18 балл белән бәйләнә.

Гомуми баллар саны: 32 балл.

## 1 НЧЕ БҮЛЕК

**Биремдәге сорауга җавап бирегез. Тиешле стильдә махсус бланкларда 140-190 сүздән торган текст языгыз.**

**1** **Әйләнә-тирә мохит турында эссе языгыз. Таяныр өчен тәкъдим ителгән сүзләрне файдаланып, үз фикерегезне дәлилләгез.**

Әйләнә-тирә мохитны саклау бүгенге көндә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Сез ничек уйлыйсыз: экологик проблемаларны хәл итәргә мөмкинме? Фикерегезне дәлилләгез.

Сүзләр

1. Һаваның пычрануы
2. Елга-күлләрне саклау
3. ……………….. (сезнең идея)

## 2 НЧЕ БҮЛЕК

**Биремдәге сорауга җавап бирегез. Тиешле стильдә махсус бланкларда 140-190 сүздән торган текст языгыз.**

**2** **Сез “Китап” журналында бер белдерү күрдегез, ди. Бу белдерү белән танышыгыз һәм бәяләмә языгыз.**

**“Елның иң яхшы китап укучысы” конкурсы**

Казанда Татарстандагы Әдәбият һәм сәнгать елы кысаларында “Елның иң яхшы китап укучысы” конкурсы игълан ителә. Конкурсны оештыручы – Татарстан Республикасы Милли китапханәсе. Конкурсның максаты – матур әдәбият укуга җәлеп итү, китап укуның дәрәҗәсен һәм культурасын арттыру, китапка карата кызыксыну уяту.

Һәрбер кеше елның иң яхшы укучысы була ала. Моның өчен үзегез яратып укыган бер китап турында бәяләмә языгыз. Төп герой сезне кайсы ягы белән гаҗәпләндерде? Һәм ни өчен? Башкаларга да бу китапны укырга тәкъдим итегез. Бәяләмәләрегезне Director.Nbrt@tatar.ru адресына юллый аласыз.

**Иң яхшы бәяләмәләр “Китап” журналында басылачак.**